# Татар теле һәм әдәбиятыннан биремнәр
# һәм методик киңәшләр

Казан
КДУ нәшрияты

PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Төзүчеләре:** филол. фәнн. канд., доцент Н.М.Гафиятуллина
филол. фәнн. канд., ассистент Э.Н.Федорова

**Фәнни мөхәррирләре**: филол. фәнн. докт., профессор Д.Ф.Заһидуллина
филол. фәнн. канд., доцент Ә.Ш.Йосыпова

Кулланма татар филологиясе һәм тарихы факультетының әзерлек курсы укучыларына, югары уку йортына укырга керергә әзерләнүче 11 сыйныф укучыларына һәм, гомумән, татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Эчтәлек**

Кереш сүз.......................................................................................3
Әдәби әсәрләр исемлеге...................................................................5
Татар әдәбиятыннан җавапларга таләпләр...........................................9
Татар әдәбиятыннан биремнәр.........................................................11
Әдәби төрләргә анализ юллары........................................................16
Әдәби әсәр анализлаганда файдалану өчен терәк схема үрнәкләре..........18
Татар теленнән биремнәрне үтәү өчен методик күрсәтмәләр...................20
Татар теленнән кыскача программа...................................................21
Лингвистик тикшерү үрнәкләре.........................................................26
Татар теленнән биремнәр.................................................................29
Өстәмә әдәбият исемлеге.................................................................46

## Кереш сүз



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

Ярдәмлек татар филологиясе һәм тарихы факультетының әзерлек курсы укучыларына һәм, гомумән, югары уку йортына укырга керергә әзерләнүче 11 сыйныф укучыларына тәкъдим ителә.  Кулланманың төп максаты – укучыларның белемнәрен системага салырга ярдәм итү, күзаллау булдыру, чыгарылыш һәм югары уку йортына керү имтиханнарына әзерләнергә  юнәлеш бирү. Контроль эшкә тәкъдим ителгән сораулар һәм биремнәр мәктәптә алган белемнәрне искә төшерү, истә калдыру һәм системага салу максатыннан билгеле бер тәртиптә бирелә.

**Татар әдәбиятыннан** сораулар сүз сәнгатенең борынгы чорыннан башлап, хәзерге әдәбиятка кадәрге дәверне иңли, чорлар арасындагы күчеш һәм бәйләнеш, традицияләрне күзалларга ярдәм итә. Язма һәм телдән  имтихан тапшыру, биремнәрне башкару өчен абитуриентның әдәби әсәр текстларын төгәл һәм җентекле белүе таләп ителә. Шул җәһәттән ярдәмлекнең беренче өлешендә мөстәкыйль әзерлек һәм керү имтиханнары өчен кирәкле, мәҗбүри булган әдәби әсәрләр исемлеге бирелде.

Укучыларга юнәлеш бирү максатыннан урнаштырылган  таләпләр өлешендә эшләрне бәяләү критерийлары, җавапларга куела торган төп таләпләр ассызыкланды, һәр сорауга якын килү, җавап язу тәртибе, эзлеклелеге кебек мәсьәләләр җентекләп яктыртылды.

Югары уку йортына керү имтиханнарында әдәби әсәргә анализ, буш, гомуми сүзләр, эчтәлек сөйләүне түгел, ә төр һәм жанр, образлар системасы бирелеше ноктасыннан төгәлләштерүне, тирәнәйтүне таләп итә. Ләкин, кызганычка каршы, мәктәп укучысының әсәрне мөстәкыйль аңлау-анализлау күнекмәсе җитми. Шуны күздә тотып, ярдәмлек һәр әдәби төргә анализ бирү юллары, тәртибе, үзенчәлекләре белән дә тулыландырылды, әдәби әсәр анализлаганда файдалану өчен терәк схема үрнәкләре белән киңәйтелде.

Хәзерлек курслаларында читтән торып укучылар **татар теленнән** 4 контроль эш башкаралар. Алар биремнәр рәвешендә тәкъдим ителәләр һәм тел белеменең төрле тармаклары буенча төркемләп төзелгәннәр. Беренче эш – фонетикага, икенче эш – лексикология тармагына, өченче һәм дүртенче контроль  эшләр грамматикага



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

багышлана. Татарча дөрес язу күнекмәләре булдыру максатыннан, һәр эштә орфографик күнегүләр тәкъдим ителә. Контроль эшләрнең барысы да тест башкару белән тәмамлана



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## Әдәби әсәрләр исемлеге

**Кол Гали.** Кыйссаи Йосыф.

**Сәйф Сарай.** Гөлстан бит-төрки. Сөһәйл вә Гөлдерсен.

**М.Болгари.** Нәһҗел - фәрадис. **"Идегәй"** дастаны.

**Мөхәммәдьяр.** Төхфәи мәрдан. Нуры содур.

**М.Колый.** Хикмәтләр.

**Г.Утыз-Имәни.** Гыйлемнең өстенлеге турында. Егет булу турында. Хатыны Хәмидәгә мәрсиясе.

**Г.Кандалый.** Тотынышып кулың кулга... Бу илләрдә торып калсам...' Сәлам яздым сиңа җаным... Сәхибҗәмал. Якутлар табыладыр... Бу хәсрәтләр бетәр микән... Сабырлык бирсәнә Алла...

**М.Акмулла.** Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе. Нургали хәзрәткә.

**К.Насыйри.** Әбүгалисина кыйссасы. Кырык бакча (берничә хикәят - сайлап).

**М.Акъегетзадә.** Хисаметдин менла.

**З.Бигиев.** Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә. Зур гөнаһлар.

**Р.Фәхретдин.** Әсма, яки Гамәл вә җәза.

**Ф.Кәрими.** Салих бабайның өйләнүе. Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы.

**З.Һади.** Җиһанша хәзрәт (абитуриент сайлавы буенча бер-ике әсәр).

**Г.Исхакый.** Кәҗүл читек. Ике йөз елдан соң инкыйраз. Кияү. Сөннәтче бабай. Ул әле өйләнмәгән иде. Көз. Өч хатын белән тормыш. Алдым-бирдем. Зөләйха. Җан Баевич. Олуг Мөхәммәд.

**Г.Тукай.** Туган авыл. Шүрәле. Су анасы. Пар ат. Милли моңнар. И каләм. Дустларга бер сүз. Хөррият хакында. Бер татар шагыйренең сүзләре. Туган тел. Сәрләүхәсез. Көзге җилләр. Мужик йокысы. Милләтә. Көз. Сорыкортларга. Татар яшьләре. Пыяла баш. Китмибез. Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре. Печән базары яхут яңа Кисекбаш. Исемдә калганнар. Халык әдәбияты.

**Ф.Әмирхан.** Нәҗип. Кадерле минутлар. Чәчәкләр китерегез миңа. Хәят. Фәтхулла хәзрәт. Яшьләр. Шәфигулла агай.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Г.Ибраһимов.** Яз башы. Көтүчеләр. Карт ялчы. Табигать балалары. Яшь йөрәкләр. Алмачуар. Кызыл чәчәкләр. Казакъ кызы.

**Ш.Камал.** Буранда. Уяну. Сулган гөл. Курай тавышы. Акчарлаклар.

**Дәрдемәнд.** Кораб. Рәсем. Шагыйрьгә. Каләмгә хитаб. Видагъ. Тал чыбык. Бүзләрем маналмадым. Без. Яз чәчәге. Тел - илнең колагы. Атам-анам йорты өчен. Татар утлы татармын. Урысча күп сүзең. Куанды ил. Җәй үтте.

**С.Рәмиев.** Таң вакыты. Уку. Авыл. Мин. Син. Ул. Мин үләм. Сызла, күңлем. Дөньяга.

**Ш.Бабич.** Мандолин. Бер минут. Халкым өчен. Хөррият бүләге. Кем өчен.

**М.Гафури.** Шатлык шигыре. Татар хатыны. Вөҗдан теләге. Хөррият иртәсе Татар җегетенә. Үзем һәм халкым. Сөембикә манарасы. Хакыйкать турында. Кызыл байрак. Кара йөзләр.

**Н. Думави.** Яз. Золым. Мәхбүс дустыма. Сугыш. Сугыш тәэссораты. Син -кеше. Үтте, үтә. Авыл малайларының ягъмур теләве.

**Г.Камал.** Беренче театр. Бүләк өчен. Банкрот.

**Г.Коләхмәтов.** Ике фикер. Яшь гомер.

**М.Фәйзи.** Галиябану.

**Һ.Такташ.** Газраиллар. Урман кызы. Таң кызы. Мәңгелек әкият. Такташ үлде. Давылдан соң. Әйдә, энем. Җырланачак җырлар турында. Бүгенге матурлык. Болай... гади җыр гына. Ак чәчәкләр. Үтеп барышлый. Алсу. Мәхәббәт тәүбәсе. Киләчәккә хатлар.

**К.Тинчурин.** Американ. Сүнгән йолдызлар. Зәңгәр шәл.

**Г.Кутуй.** Тапшырылмаган хатлар. Сагыну. Без - сталинградчылар.

**М.Җәлил.** Хат ташучы. Алтынчәч. Хуш, акыллым. Окоптан хат. Дуска. Кичер, илем! Кошчык. Бүреләр. Төрмәдә төш. Вәхшәт. Җырларым. Кызыл ромашка. Ана бәйрәме. Тау елгасы. Имән. Сандугач һәм чишмә.

**Ф.Кәрим.** Кыр казы. Үлем уены. Ант. Урман тын иде. Юл. Иптәш. Сөйләр сүзләр бик күп алар... Сибәли дә сибәли. Моң һәм көч. Мин - гуманист. Гөлсем. Партизан хатыны. Тимер һәм тимерче. Кыңгыраулы яшел гармун. Пионерка Гөлчәчәккә хат. Разведчик язмалары.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Н.Исәнбәт.** Хуҗа Насретдин. Идегәй.

**Г.Бәширов.** Туган ягым - яшел бишек. Намус.

**Ә.Еники.** Бала. Ана һәм кыз. Бер генә сәгатькә. Кем җырлады? Әйтелмәгән васыять. Матурлык. Туган туфрак. Рәшә. Гөләндәм туташ хатирәсе.

**Х.Туфан.** Ак каен. Каеннар сары иде. Илдәниләр бар икән? Агыла да болыт агыла. Кайсыгызның кулы җылы? Иртәләр җитте исә... Сиңа. Гөлләр инде яфрак яралар. Сөйли торган материя. Киек казлар. Әйткән идең... Туган тел турында җырлар. Кармәт истәлекләре. Чәчәкләр китерегез Тукайга.

**С.Хәким.** Юксыну. Пар ат. Дуга. Башка берни дә кирәкми. Үрләреңне менгәч. Гел кояшка карый тәрәзәләрең. Әнкәй. Сусау. Һәйкәл урынында уйланулар. Кырыгынчы бүлмә.

**Х. Вахит.** Беренче мәхәббәт.

**Г.Ахунов.** Хәзинә.

**Н.Фәттах.** Итил суы ака торур. Сызгыра торган уклар.

**А.Гыйләҗев.** Язгы кәрваннар. Җомга көн кич белән... Әтәч менгән читәнгә. Өч аршын җир.

**М.Мәһдиев.** Без - 41 ел балалары. Торналар төшкән җирдә. Кеше китә - җыры кала. Бәхилләшү.

**И.Юзеев.** Таныш моңнар. Бакчачы турында баллада. Өзелмәс кыллар. Өчәү чыктык ерак юлга. Очты дөнья читлегеннән. Гашыйклар тавы.

**Ш.Хөсәенов.** Әниемнең ак күлмәге (Әни килде).

**Т.Миңнуллин.** Үзебез сайлаган язмыш. Әлдермештән Әлмәндәр. Әниләр һәм бәбиләр. Илгизәр плюс Вера.

**Р.Батулла.** Кичер мине, әнкәй! Сират күпере.

**Р.Хәмид.** Олы юлның тузаны. Җиде баҗа (бер-ике әсәр абитуриент сайлавы буенча).

**Р.Фәйзуллин.** Минем әти. Яздан аерып булмый Тукайны. Якты моң. Җаныңның ваклыгын.. Мин сиңа йомшак таң җиле...Үлем һәм үлемсезлек. Минем телем. Сәйдәш. Гадиләргә гимн.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Р.Харис.** Дөньям кызыксындыра. Ат иярләү. Ак сөлге. Ант суы. Кеше. Хәтер көне. Сусап кил. Кыргый кыз.

**М.Әгъләмов.** Еракка китеп кара. Бары шул. Тукайдан хатлар. Акмулла арбасы. Замандашым монологы. Иман тәрәз шакый. Каеннар булсаң иде...

**Ш.Галиев.** Шәвәли маҗаралары. Камырша. Утсыз төтен булмый. Үзең нинди. Физзарядка ясый куян. Кыңгыраулы мәктәп еллары.

**Р.Миңнуллин,** Энекәш кирәк миңа. Әни, мин көчек күрдем. Әти төсле. Батырлык эшләр идем. Шундый минем туган ягым. Кайтыйк ла үзебезгә. Кем нәрсә тарта? Әнкәмнең догалары (абитуриент сайлавы буенча бер шагыйрь әсәрләре).

*Хәзерге татар поэзиясе вәкилләреннән шигъри әсәрләр:*

**1. Ә.Баян.** Сәяхәтнамә. Көзге урман. Төнге бәхәс. Сез аңларсыз мине һ.б.

**2. С.Сөләйманова.** Туган җирем, эчкән суым! Кеше барыбер кошлар нәселеннән. Сулар ага, күлләр күккә бага... Тагын узды кыңгыраулы язлар...һ.б.

**3. Г.Афзал.** Дөнья матур, дөнья киң. Өф-өф итеп. Мыек борам. "Кызыл балчык" промартелендә. Ачы язмышлар. Татарстан таңнары һ.б.

**4. Ф.Яруллин.** Әйбәт тә минем әби. Ак төнбоек. Сез иң гүзәл кеше икәнсез. Көрәшче һ.б.

**5. Зөлфәт.** Йөрәкләрдә үлмәс дастан. Кара күбәләк. Адашкан болыт. Имансызлар. Туфрак тарта. Язмыш. Ходай сулышы. Тылсым. Дүрт җыр һ.б.

*Хәзерге татар прозасы буенча тәкъдим ителгән һәр тема буенча бер-ике әсәр:*

1. Татар халкының үткән тарихы **(М.Хәбибуллин.** Кубрат хан. Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный. **Р.Батулла.** Сөембикә. **Ф.Латыйфи.** Хыянәт. **Ф.Сафин** Саташып аткан таң.)

2. Тарихыбызда тирән эз калдырган олы шәхесләрнең әдәби образлары (**Р.Мөхәммәдиев.** Сират күпере. **Җ.Рәхимов.** Батырша. **В.Имамов.** Сәет батыр.)

3. Тоталитар системаның кешелексез якларын фаш итү **(И.Сәләхов.** Тайгак кичү. **Г.Тавлин.** Афәт. **А.Гыйләҗев.** Йәгез, бер дога.)



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

4. XX гасырның 20-30 елларындагы халык тормышына бәйле кеше һәм җәмгыять каршылыгын яңача бәяләү **(Г.Ахунов.** Идел кызы. **М.Хәсәнов.** Язгы аҗаган.)

5. Бөек Ватан сугышы **(Г.Әпсәләмов.** Алтын Йолдыз. **М.Юныс.** Шәмдәлләрдә генә утлар яна. **Х.Камалов.** Һәркемнең гомере бер генә.)

6. Совет чоры җәмгыятенә бәя **(Р.Мөхәммәдив.** Кенәри - читлек кошы. **А.Гыйләҗев.** Балта кем кулында? Яра. **Ф.Садриев.** Бәхетсезләр бәхете.)

7. Әхлакый кыйммәтләрне яклау **(Х.Сарьян.** Бер ананың биш улы. **Р.Мөхәммәдиев.** Ак кыялар турында хыял. **Ф.Садриев.** Таң җиле. **М.Маликова.** Шәфкать. **З.Хәким.** Гөнаһ.)

**Халык авыз иҗаты үрнәкләре.** Әкиятләр. Легенда һәм риваятьләр. Дастаннар. Мәзәкләр. Җырлар. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Бәетләр ("Сөембикә бәете", "Сак-Сок бәете").

## Татар әдәбиятыннан җавапларга таләпләр

Тәкъдим ителгән биремнәр укучыларның нәзари (теоретик) белемнәрен; әдәби барышны, аерым бер әдипнең иҗат үзенчәлекләрен бәяләү, әдәби әсәр белән эшләү мөмкинлекләрен; әсәргә яки чорга шәхси фикерен, мөнәсәбәтен белдерә алу сәләтен ачыклау максатларын күздә тотып эшләнде. Иң беренче чиратта, әдәби әсәрләрне кабат укып чыгу, тәнкыйди материаллар белән танышу, алар турында шәхсән уйлану киңәш ителә, чөнки җавапларда дәреслек материалын гына күчереп кую үзен акламый, әзерлек дәрәҗәсен дә арттырмый, өстәвенә билгене дә түбәнәйтә. Иң мөһиме: җаваплар укучының, дәреслек материалына һәм тәнкыйди язмаларга таянып, үз шәхси бәясен, фикерләү дәрәҗәсен чагылдырырга тиеш. Җаваплар озын булмыйча, төгәл һәм тәмамланган фикерләрдән торса яхшы. Биремнәрдәге һәр сорауга төгәл, дәлилле җавап таләп ителә.

Беренче сорау укучының теоретик төшенчәләрне аңлау дәрәҗәсен ачыклауны күздә тота. Укучы теге яки бу теоретик төшенчәгә дәреслектән коры билгеләмәне



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

генә күчереп куярга түгел, ә бәлки, аның төп сыйфатларын күрсәтелгән әсәр нигезендә дәлилли алырга тиеш.

Икенче сорау билгеләнгән әдип иҗатына яки бер әсәргә бәя бирүне күздә тота, төгәллекне, теоретик материалны белеп, дөрес куллануны сорап тора. Җавап эчтәлек сөйләүгә кайтып калмасын, авторның әйтергә теләгән фикерен, үз караш-мөнәсәбәтеңне ачыклау юнәлешендә булсын. Һәр фикер конкрет фактлар, әсәрдән мисаллар, фрагментлар белән ныгытылсын. Әдәби әсәрнең поэтик үзенчәлекләрен, язучының стилен, төп иҗади сыйфатларын бәяләү шул дәвердәге әдәби-тарихи контекст белән бәйләп алып барылса яхшы.

Өченче сорау аерым бер чорга бәя бирүне алга куя. Бу сорауга җавап бирү барышында чорның төп тарихи һәм иҗтимагый вакыйгаларын, аларның шул чор сәнгатенә йогынтысын ассызыклап, күрсәтелгән вакыт аралыгында әдәбиятның төп сыйфатларын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, үзенчәлекләрен аерып чыгару, өстенлек иткән иҗат юнәлешен, агымнарын, әдәби жанрларны, күтәрелгән тема-проблемаларны ачыклау, дәвернең сүз осталарын санап китү, аларның чор әдәбиятында тоткан урынын билгеләү сорала. Өченче һәм дүртенче биремнәрдә ул, киңрәк характерда булып, баланың хәзерге әдәби процесс белән танышлыгын, әдәбияттан мәгълүматын, шәхси мөнәсәбәтен, логик фикерләү дәрәҗәсен, иҗади мөмкинлекләрен, дөньяви эрудициясен дә ачыклауны күздә тота. Җавапта күрсәтелгән әсәргә һәм чорга үз бәяңне бирү мөһим.

Дүртенче сорау укучыларның әдәби әсәргә анализ ясау дәрәҗәсен, нәзари (теоретик) белемнәрен ачыклау максатыннан анализга һәр әдәби төрдән бер әсәр тәкъдим итә. Эпик әсәргә анализ барышында төп теоретик төшенчәләр аша автор фикерен, сюжет сызыкларын, каршылыкны, тема-проблеманы аерып чыгару, әсәргә үз карашыңны һәм мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрнең актуальлеген билгеләү сорала; лирик әсәрләргә анализда төп лирик мотивларны аерып чыгару, лирик геройның хис-кичерешен, аның сәбәпләрен ачыклау таләп ителә; драма әсәрләренә анализның төп эчке һәм тышкы каршылыкларны ачыклау, образларга характеристика бирү, автор фикерен-идеясен ачыклау юнәлешендә алып барылуы мөһим.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

Өченче биремдә исә дүртенче сорауга сочинение темалары тәкъдим ителде. Сочинение кереш, төп өлеш һәм йомгактан тора. Кереш, озын булмыйча, төп өлешкә җирлек әзерли, фикерне башлап җибәрә. Төп өлештә исә әсәргә яки әдип иҗатына төгәл анализ ясала, тема ачыла, фикерләрнең әсәрләрдән мисаллар белән дәлилләнүе сорала. Йомгакта төп фикерләр гомумиләштерелә. Сочинениедә төп фикер аерылып торырга, буш, гомуми сүзләр белән чуарланмаска тиеш. Цитаталар һәм эпиграфларны төгәл хәтерләгәндә, урынлы булганда гына куллану киңәш ителә.

Укучы һәр биремне күрсәтелгән тәртиптә башкарырга тиеш. Һәр биремнең җаваплары 12 битлек гади дәфтәр күләменнән дә артмасын. Алдан ук куелган билгеләрнең үзегез өчен, белем дәрәҗәгезне билгеләү өчен генә икәнлеген искәртәбез.

## Татар әдәбиятыннан биремнәр

### 1-бирем

1. З.Бигиевның "Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә" повесте мисалында мәгърифәтчелек реализмына хас сыйфатларны санагыз.
2. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында нинди сыйфатлар каршылыкка керә? Әсәрнең бүгенге көн укучысы өчен әһәмияте нидән гыйбарәт?
3. XVIII гасыр әдәбиятына хас төп үзенчәлекләрне билгеләгез, фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.
4. Шигырьгә анализ ясагыз.

***РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН***

**Якты моң**

Күчә җилдә ак комнар.
Ярга кага дулкыннар.
Акчарлаклар Иделдә.
Туган илем күңелдә.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

Чык ялтырый гөлләрдә

Аяз таңлы көннәрдә.

Алтын кояш күгемдә.

Газиз әнкәм күңелдә.

Җилкәннәрдә җил бәрә.

Ярда рәшә тирбәлә.

Рәхәт Туган җиремдә!

Сөйгән ярым күңелдә.

**2-бирем**

1. Ф.Әмирханның “Хәят” повесте мисалында сюжет һәм сюжет элементлары хакында языгыз.
2. Һ.Такташ иҗатында нинди шартлы-символик образлар кулланыла, автор алар аша нинди фикерләр үткәрә? Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.
3. XX йөз башы драматургиясенә бәя бирегез.
4. Хикәягә анализ ясагыз.

## *ГАЛИ РӘХИМ*

### Яз әкиятләре

Яз көне иде. Кояш кыздырмаенча гына җылыта иде. Кечкенә генә канәфер агачының бөреләре ярылып, юка гына, йомшак кына яфракчыклар кояшка таба башларын суза башладылар. Шул чакта канәфер агачының янында гына юеш, парлы бакча туфрагыннан эт эчәгесе куркынып кына тишелеп чыкты. Тишелеп чыкты да, гаҗәпләнеп, тирә-ягына карана башлады. Башын югарыга күтәргән иде, кояшны күрде. Шул чакта ул әллә нинди бер билгесез көчнең үзен кояшка таба омтылдырганын сизде.

Эт эчәгесе, яфракларын җәеп, кояшка үрелергә тотынды. Ул, кояшка бик тиз җитәрмен, дип, тиздән аны кочармын-үбәрмен, дип уйлый иде. Ул җилкенгәннән-җилкенә, үрелгәннән-үрелә иде.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

Менә ул кинәт үзендә бер төрле авырлык сизә башлады. Аның сыны калтырый иде. Ул түбән таба карады. Үз уенча инде ул җирдән әллә никадәрле ерак киткән булырга тиеш иде. Ләкин алай булып чыкмады. Ул әле җирдән бер генә карыш күтәрелгән иде. Ул башын бөкте дә уйга калды.

Күз алды караңгыланып китте. Аның нигә булса да таянасы, тотынасы килә иде. Эт эчәгесе үзенең җиргә ауганын сизми дә калды. Ул үзен бик зәгыйфь, бик көчсез хис итә иде. Ул көчкә генә башын күтәрде дә чиксез кайгы белән батып бара торган кояшка карады. Аның яңа гына чыгып килә торган, кан күк кызыл, күбәләк канаты шикелле юка яфраклары дерелдәп киткән күк булдылар. Ул озак вакыт карап торды да, ишетелер-ишетелмәс аваз белән:

— Ник мине калдырасың? Ник мине күтәрмисең? Ник мине алмыйсың? — диде.

Кояш батты. Караңгылык төшә башлады. Чык төшеп, әлсерәгән үләннәрне, сусаган яфракларны чылатты. Алар кыйбладан искән кичке җылы җил белән акрын гына калгып йоклый башладылар.

Эт эчәгесе хәл алды да тагын башын күтәрде. Ачык күктән күренер-күренмәс кенә йолдызлар җылтыр-җылтыр итеп түбән таба карыйлар, парлы, җылы җил эт эчәгесенең нәфис яфракларын сыйпый иде. Менә бер заман әллә кайдан искиткеч авазлар ишетелә башлады. Каршы бакчада сандугач сайрарга тотынган иде. Ул әллә нинди билгесез тойгылар, булуы мөмкин булмаган хыяллар турында җырлый иде.

Эт эчәгесе як-ягына каранды да янында гына рәхәт йокыга талган кечкенә генә канәфер агачын күрде. Салкын чык аңар көч бирде. Төннең караңгылыгы аны җөрьәтләндерде. Ул салына алган чаклы салынып җиргә ятты да, кара елан шикелле борылып-сарылып, яшь канәфер агачына таба үрмәли башлады. Менә ул аның төбендә инде. Ул башын күтәрде дә, тавышына дәртле аһәң биреп, шыпырт кына:

— Сөям!.. — диде. Башка сүз әйтмәде.

Канәфер агачы сизелмәслек кенә калтыранып китте. Ул төш күрә иде. Төшендә кояшка сарыла иде, аны үбә иде, аңар мәхәббәт сүзләре сөйли иде.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

—Сөям!..

Бу тавыш аны әллә нишләтеп җибәрде. Бөтен төшенә электрик йөгергән төсле булды. Ул уянды.

—Сөям!..

Канәфер агачы гаҗәпләнеп аска таба карады. Бу сихерле тавыш түбәннән килә иде. Эт эчәгесе белән зифа канәфер агачы күзгә-күз очраштылар. Канәфер агачы дерелдәде дә ...

— Кем син? Син әллә чынлап та минем сөйгәнемме? Син миңа төшемдә дә килгән идең түгелме? Ник дәшмисең? Ник җавап бирмисең?

Аның ялкынлы сүзләренә эт эчәгесе бер сүз белән җавап бирде:

— Сөям!

Канәфер агачы тагын дерелдәде.

— Сөямсең?.. Алдашмыйсыңмы?.. Мин ышанмыйм сиңа.

— Син ышанмыйсың? Кара күккә, ул ни өчен шундый ялтыравыклы йолдызлар белән бизәлгән? Безнең сөешүебезне котлар өчен генә. Бу йомшак җил ни өчен исә? Бары безнең икебезне иркәләр өчен генә. Тыңла! Бу сандугач ник бу хәтле йөрәккә үткәреп сайрый? Чөнки аның сайравы безнең мәхәббәтебез өчен генә, безнең мәхәббәтебез өчен генә.

Канәфер агачы эт эчәгесенең сүзләренә ышанды. Парлы төнге һава һәм мәхәббәт аны бөтенләй исерткәннәр иде. Ул эт эчәгесенең сүзләрендә алдау булыр дип уйлый алмый иде. Ул, гыйшкының катылыгыннан калтыранган һәм чак ишетелерлек тавыш белән:

— Соң ни өчен алай булгач мине кочагыңа алырга ашыкмыйсың? Ни өчен ашыкмыйсың?.. — диде.

Эт эчәгесе канәфер агачының бер ботагын кочаклап кысты. Канәфер агачының тагы бөтен төше ут белән тулды. Ул тагы дерелдәде. Аның яңа гына ачылып килә торган яфракларыннан чык тамчылары тәгәрәп төштеләр... Иртә белән чыккан кояш аларны бер-берсенә сарылышкан хәлдә күрде.

Көннәр үтте. Эт эчәгесе канәфер агачының ботакларына чолганганнан-чолгана бара иде. Көннәр үткән саен, канәфер агачының яфраклары



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

куера бара, аның яфраклары куерган саен, эт эчәгесенең кочышлары кызулана бара иде. Ул канәфер агачының чыбыкларына җан ачысы белән тотынган күк тотына вә өскә чыгарга тырмаша иде.

Менә беркөнне канәфер агачының яфраклары аркылы кояш нурлары үтми башлады. Эт эчәгесе актык көче белән талпынды, канәфер яфракларын үтеп, кояш яктылыгына чыкты. Чыккач, ул чиксез мәхәббәт белән кояшка карап торды. Озак карап торды да:

— Сөям!.. Кояш, сине генә сөям! Никадәр мәшәкать чиксәм — һәммәсен синең өчен генә чиктем, — диде.

Эт эчәгесенең яфраклары як-якка тарала башладылар. Алар инде канәфер агачының бөтен яфракларын күләгәдә калдырганнар иде. Канәфер агачы актык чиккә кадәр түзде. Ахырдан чыдый алмады:

— Мин үләм!.. Миңа кояш калмады!.. Мине аз гына сөйсәң, бер генә ботагымны кояш астына чыгар, — диде.

Эт эчәгесе аңар сөкүт (эндәшмәү) белән җавап бирде. Бары аның яңа ачылган чәчәкләре әллә кайдан килгән бу ят тавышка гаҗәпләнеп башларын селкеделәр.

Канәфер агачы актык сулышын җыйды да:

— Үләм!.. Бер генә тамчы кояш нуры!.. — дип кычкырды. Аның кычкыруыннан сискәнеп, бакчадагы агач яфраклары шыпырдаштылар. Сандугач, куркып, күкрәк төбеннән «фьют» дигән аваз чыгарды да сайравыннан туктады. Ул инде артык сайрый алмады, чөнки, куркуыннан, саташкан, сакауланган иде, әмма эт эчәгесенең яфраклары бары шаркылдашып көлештеләр генә.

Канәфер агачының эчендә актык мәхәббәт очкыны сүнде. Аның яфраклары — шиңеп, нәфис яшел ботаклары салынып төштеләр. Ул үлде...

### 3-бирем

1. Х.Туфанның “Илдәниләр бар икән?” шигыренә нигезләнеп, шигырь төзелешенә хас үзенчәлекләр турында языгыз.
2. Ә.Еникинең “Матурлык” хикәясендә автор нинди сыйфатларны Матурлык дип саный? Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

3. **Иҗади эш**. Г.Бәшировның “Намус” романына бүгенге көн күзлегеннән бәя бирегез.

4. Сочинение темалары (берсен сайлап алыгыз):

- М.Җәлил шигъриятендә лирик герой бирелеше;
- М.Колый хикмәтләрендә суфыйчылык мотивлары;
- Г.Исхакыйның “Ике йөз елдан соң инкыйраз” әсәрендә татар тормышы турында уйланулар;
- С.Хәким – туган як җырчысы.

**4-бирем**

1. И.Юзеевның «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы мисалында романтик әсәрләргә хас үзенчәлекләрне билгеләгез.

2. А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә” повестенда күтәрелгән проблемаларны санагыз, фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

**3.** **Иҗади эш.** Бүгенге прозага (1990-2005) бәя бирегез.

4. Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” әсәренә анализ ясагыз.

**Әдәби төрләргә анализ юллары.**

**Лирик әсәрнең** нигезендә хис-кичереш ята. Аларны анализлауның иң киң таралган юлы — «автор артыннан бару». Ул строфадан строфага лирик геройның *хис-кичереш күчешен* һәм *аның сәбәпләрен*, поэтик образлар, яки башка элементлар аша *хиснең дәрәҗәсен* билгеләү, *юану* өлешен ачыклау, шигырьдән алган тәэсирне ассызыклау юнәлешендә алып барыла. Моннан тыш жанры, ритм-рифмалар, символ-метафоралар аша үткәрелгән мәгънә, *автор фикере*, *темасы* күзәтелә. Шигырьнең темасы хиснең сәбәбе белән бәйле була.

**Эпик төргә** исә вакыйгалылык хас. Шуңа да эпик әсәргә анализ сюжетны күзәтүдән башлана һәм төп *сюжет сызыкларын* билгеләү, андагы каршылык үсеше аша *сюжет элементларын* ачыклау, *образларга характеристика* бирү юнәлешендә алып барыла. Төп каршылыкны ачыклау *теманы* табарга ярдәм итә, аны тудыручы сәбәпләр еш кына *проблема* булып төгәлләшә. Эпик әсәрдә тема, үз чиратында,



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

идея белән бәйләнештә була. Проблема дәрәҗәсендә куелган сорауларга автор идея катламында җавап таба. Биредә теге яки бу мәсьәләгә *автор мөнәсәбәтен*, *әдипнең позициясен*, бәясен ачыклау мөһим. Геройларга һәм әсәрнең композициясенә бәя бирү барышында геройларның *портретына*, *пейзажга*, *вакыйгаларның бару урынына*, *психологизмга* - халәт, эчке дөнья, кәеф үзгәрешенә һ.б., әйберләр дөньясына игътибар итү сорала. Алар аркылы язучының иҗади осталыгы, *язу стиле* билгеләнә һәм әсәргә укучының үз шәхси мөнәсәбәте, бәясе урын ала.

**Драма әсәрләренә** анализ тышкы һәм эчке каршылыкларны аерып алудан башлана. *Герой белән герой*, *герой белән тирәлек*, *герой белән җәмгыять* арасындагы *тышкы* яки *төп герой күңелендә* барган *эчке каршылыкларда* җәмгыятькә хас *проблемалар* калкытып куела. Төп каршылыкның сәбәбе еш кына *проблема* булып төгәлләшә. Конфликт барлык персонажларны хәрәкәткә китерә, аларның характерын ачарга ярдәм итә. Шуңа да анализ барышында конфликт үсешен һәм герой характерларын янәшә куеп тикшерү отышлы санала. Драма әсәренә дә сюжетлылык хас. Конфликтның үсеш-үзгәреш тарихын күзәтү *сюжет элементларын* билгеләргә ярдәм итә. Драма әсәрендә *автор фикере*, *идея* исә персонажлар сөйләме, эш-гамәлләре аркылы үткәрелә.

***Төп әдәбият***:


1. Есин А. Принципы и приемы анализа литературного произведения / Есин А. – М.: Флинта, Наука, 2002. – 248 с.
2. Заһидуллина Д. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы / Д.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.
3. Заһидуллина Д. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. / Заһидуллина Д., Закирҗанов Ә., Гыйлаҗев Т. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.




PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Әдәби әсәр анализлаганда файдалану өчен**

**терәк схема үрнәкләре:**

**Чәчмә әсәр анализлау планы**

1. Әсәрнең язылу вакыты, тарихы (билгеле һәм кирәк булса).
2. Төп әдәби образлар системасы. Аларны сыйфатлау.
3. Сюжет бирелеше. Конфликт.
4. Әсәрнең тема, проблема, идеясе.
5. Сурәтләнгән дөнья ( пейзаж, портрет, әйләнә-тирә дөньяны тасвирлау).
6. Әсәрнең композициясе.
7. Әсәрнең теле (автор сөйләме, хикәяләү, сурәтләү, персонажлар сөйләме, тел-сурәтләү үзенчәлекләре).
8. Жанры.
9. Әсәрнең язучы иҗатында тоткан урыны.
10. Татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы.

**Лирик шигырь анализлау планы.**

1. Язылу вакыты. Реаль-биографик һәм фактологик аңлатмалар (билгеле һәм кирәк булса).
2. Жанры.
3. Лирик геройга бәя. Аның сурәтләнгәннәргә мөнәсәбәте, кичереше, фикере.
4. Тема, төп эчтәлек.
5. Хисләр бирелеше, аларның гәүдәләнеше, үсеш-үзгәреше.
6. Төп образлар, аларның әһәмияте, яңалыгы.
7. Сөйләм үзенчәлекләре, сурәтләү чаралары.
8. Әсәрнең төзелеше.
9. Шигырь төзелеше ягыннан бәя. Ритм һәм рифма.

**Драма әсәрен анализлау планы**

1. Әсәрнең язылу вакыты, тарихы (билгеле һәм кирәк булса).
2. Төп тышкы һәм эчке каршылыклар. Конфликт бирелеше.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

3. Сюжет бирелеше һәм сюжет элементлары.

4. Әсәрнең тема, проблема, идеясе.

5. Образлар системасы.

6. Әсәрнең теле (автор сөйләме, хикәяләү, сурәтләү, персонажлар сөйләме, тел-сурәтләү үзенчәлекләре).

7. Жанры.

8. Әсәрнең язучы иҗатында тоткан урыны.

9. Татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## Татар теленнән биремнәрне үтәү өчен методик күрсәтмәләр

Хәзерлек курслаларында читтән торып укучылар биремнәрне эшләгәндә, теоретик мәгълүматны искә төшерү максатаннан, 5-11сыйныфлар өчен татар теленнән мәктәп дәреслекләреннән, төрле сүзлекләрдән һәм башка кулланмалардан файдалана алалар. Шулай ук укучыларга белемнәрен системалаштыру, тирәнәйтү һәм ныгыту максатыннан, контроль эш биремнәренә кадәр кулланмада татар теленнән кыскакача программа тәкъдим ителә. Эш башлаганчы, бу программа белән җентекләп танышу һәм аңлашылмаган очракларны ачыклау сорала. Мәктәп дәреслекләрендә лингвистик анализ үрнәкләрендәге төрлелекне искә алып, бу кулланмада укучыдан сорала торган тикшерү үрнәкләре таблицасы бирелә, һәм анализларның шул тәртиптә башкарылуы таләп ителә.

Һәр эш унар биремнән һәм тестлардан тора. Биремнәр, мәктәп дәреслекләрендәгеләрдән аермалырак булганда, үрнәк күрсәтелә, һәм сездән күнегүне үрнәктәгечә үтәү сорала. Кайбер биремнәрне, үрнәктәгечә, таблица рәвешендә эшләргә кирәк. Тестларны башкарганда шуңа игътибар итегез: дөрес җавап бары бер генә була ала, һәм сез шуны гына язып җибәрергә тиеш буласыз.

Биремнәр белән башта җентекләп танышырга, теоретик материалны кабатларга һәм һәр контроль эшне аерым дәфтәргә анык, пөхтә итеп эшләп җибәрергә кирәк.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## Татар теленнән кыскача программа

### *ФОНЕТИКА*

Фонетика турында төшенчә. Сөйләм авазлары. Сөйләм органнары. Сузык һәм тартык авазлар, алар арасындагы аерма.

Сузык авазларның саны һәм составы. Рәт гармониясе, ирен гармониясе /Сингармонизм законы/. Сузыкларның кыскаруы /редукция/.

Дифтонглар. Татар телендә аларның үзенчәлеге һәм язуда бирелеше.

Тартык авазлар. Анарның саны һәм составы. Тартык авазларны төркемләү. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Сөйләмдә тартыкларның охшашлануы.

Интонация. Иҗек. Татар телендә иҗек калыплары. Басым. Татар телендә сүз басымының урыны. Басым соңгы иҗеккә төшми торган очраклар.

Орфоэпия һәм орфография. Татар телендә орфографик принциплар. Авазларны язуда күрсәтү. Алфавит. “ъ” һәм “ь” хәрефләренең дөрес язылышы.

Графика. Татар халкында язу тарихы.

### ЛЕКСИКА

Лексика телнең сүзлек составы турында төшенчә. Сүзнең мәгънәсе.

Килеп чыгышы буенча татар теленең сүзлек составы: төрки-татар сүзләре, гарәп-фарсы, рус һәм европа теленнән кергән алынмалар.

Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Омонимнар, аларның төрләре. Антонимнар. Синонимнар.

Кулланылыш сферасы ягыннан татар теленең сүзлек составы: тарихи сүзләр, архаизмнар һәм неологизмнар. Гомумкулланылыштагы сүзләр. Һөнәрчелек лексикасы. Диалекталь сүзләр.

Татар телендә фразеологик әйтелмәләр.

Лексикография. Сүзлекләрнең төрләре: аңлатмалы һәм телара сүзлекләр.

Ономастика. Аның тармаклары.

### СҮЗ ЯСАЛЫШЫ

Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр һәм кушымча.

Ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерүче (модальлек белдерүче һәм бәйләгеч) кушымчалар. Кушымчаларның вариантлары.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

Сүзнең нигезе. Сүз ясалышы ысуллары. Ясалышы ягыннан сүз төрләре. Ясалма һәм кушма сүзләр. Кушма сүзләрнең саф кушма, парлы һәм тезмә төрләре. Кыскартылма сүзләр.

Сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү. Сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү (конверсия).

## М 0 Р Ф 0 Л 0 Г ИЯ

Сүз төркемнәре турында төшенчә. Татар телендә сүзләрне төркемнәргә бүлү.

Мөстәкыйль сүз төркемнәре /исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, аваз ияртемнәре/. Бәйләгечләр /теркәгеч, бәйлек/. Модаль сүз төркемнәре /хәбәрлек сүзләр, кисәкчә, ымлык/. Ымлыклар һәм аваз ияртемнәре.

Грамматик мәгънә һәм грамматик чара.

## И С Е М

Исемнең мәгънәсе һәм грамматик билгеләре. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнең сан, килеш, тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исем ясалышы.

Фамилия ясаучы кушымчалар.

## С Ы Й Ф А Т

Сыйфатның грамматик билгеләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат һәм сыйфатланмыш.

Сыйфат дәрәҗәләре /гади, чагыштыру, артыклык, кимлек/. Сыйфатларның исемләшүе. Сыйфат ясальшы.

## С А Н

Сан турында гомуми төшенчә. Сан һәм саналмыш. Сан төркемчәләре: төп сан, тәртип, бүлем, чама,  җыю саннары.

Санның ясалышы. Саннарның дөрес язылышы.

## А Л М А Ш Л Ы К

Нинди сүз төркеме алмашлык дип атала? Алмашлыкның төркемчәләре.

Алмашлыкның төзелеше һәм дөрес язылышы.

## Ф И Г Ы Л Ь

Фигыльгә гомуми характеристика. Аның барлык-юклык, зат-сан, заман белән



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

төрләнеше. Фигыль төркемчәләре. Фигыль юнәлешләре: төп, төшем, кайтым, йөкләтү, уртаклык. Фигыльдә дәрәҗә белдерү.

Затланышлы фигыль формалары /хикәя, боерык, шарт, теләк/ һәм затланышсыз фигыльләр /сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль, инфинитив/.

Хикәя фигыльнең заман формалары.

Сыйфат фигыльнең заман формалары. Сыйфатка һәм фигыльгә хас үзенчәлекләре.

Исем фигыльдә исемгә һәм фигыльгә хас үзенчәлекләр.

Хәл фигыльнең төрләре һәм кулланылыш үзенчәлекләре.

Ярдәмче фигыльләр. Фигыльләрнең ясалышы.

## Р Ә В Е Ш

Рәвеш турында төшенчә. Аның лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик билгеләре.

Рәвеш төркемчәләре. Билге һәм хәл рәвешләре.

Рәвешнең ясалышы.

## АВАЗ ИЯРТЕМНӘРЕ

Мөстәкыйль сүз төркеме буларак аваз ияртемнәре. Аларның үзенчәлеге.

## БӘЙЛӘГЕЧ СҮЗ Т Ө Р К Е М Н Ә Р Е

Теркәгечләр, аларның функциясе. Теркәгечләрнең төркемчәләре.

Теркәгеч сүзләр. Аларның үзенчәлеге.

Бәйлек һәм бәйлек сүзләр. Үзләреннән алда килгән сүзләрнең нинди килештә булуын таләп итүдән чыгып, бәйлекләрнең төркемчәләре.

## МОДАЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ

Кисәкчәләр һәм аларның төркемчәләре. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

Хәбәрлек сүзләр турында төшенчә.

Ымлык һәм аның төрләре.

## С И Н Т А К С И С

Синтаксисның өйрәнү объекты.Төп синтаксик берәмлекләр:сүзтезмә, җөмлә, текст.

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше: тезүле һәм ияртүле бәйләнеш. Тезүле



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

бәйләнешне белдерүче чаралар. Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар. Хәбәрлекле, ачыклаулы, аныклаулы мөнәсәбәт.

Сүзтезмә. Аның төрләре.

*Гади җөмлә*

Җөмләнең баш кисәкләре. Ия белән хәбәрнең төрләре. Ия белән хәбәрнең ярашуы.

Җөмләнең иярчен кисәкләре. Иярчен кисәкләрнең төрләре: аергыч, тәмамлык, хәл кисәкләр, аныклагыч. Туры һәм кыек тәмамлыклар. Хәл кисәкләрнең мәгънә ягыннан төрләре.

Модаль кисәкләр: эндәш һәм кереш сүзләр. Аларның җөмләдәге урыны. Алар янында тыныш билгеләре.

Бер составлы (атау, фигыль, сүз) һәм ике составлы җөмләләр.

Тулы һәм ким җөмләләр.

Әйтү максатыннан чыгып җөмлә төрләре: хикәя, сорау һәм боерык җөмләләр. Өндәү җөмлә.

Җөмләдә тиңдәш кисәкләр, алар янында тыныш билгеләре.

Аерымланган кисәкләр. Җөмләдә иярчен кисәкләрнең аерымлануы, алар янында тыныш билгеләре.

Җөмләдә сүз тәртибе: туры һәм кире (инверсия)

*Кушма җөмлә*

Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Кушма җөмлә төрләре.

Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, алар янында тыныш билгеләре.

Иярченле кушма җөмләләр. Баш һәм иярчен җөмлә. Иярчен җөмләләрнең төзелеше һәм мәгънә ягыннан төрләре. Бәйләүче чараның төренә карап, татар телендә иярчен җөмләләр: аналитик һәм синтетик төзелешле иярчен җөмләләр.

Катлаулы төзелмәләр: күп иярченле кушма җөмләләр һәм аның төрләре, катнаш кушма җөмләләр.

Текст синтаксисы. Текстның бөтенлеге. Тезем.

Чит сөйләмле текст. Туры сөйләм. Кыек сөйләм. Уртак сөйләм.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## СТИЛИСТИКА

Әдәби сөйләм һәм аның төрләре. Сөйләм стиленең төрләре һәм үзенчәлекләре: әдәби, публицистик, фәнни, рәсми, сөйләмә стильләр.

Сөйләм культурасы. Сөйләм төгәл булсын. Сүз тәртибе һәм сөйләм төгәллеге. Сөйләм аңлаешлы булсын. Сөйләм саф булсын. Сөйләм җыйнак булсын. Сөйләм аһәңле булсын.

Тел — иҗтимагый күренеш. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат. Татар әдәби теленең үсеше: гомумтөрки әдәби тел, борынгы төрки тел, иске төрки тел, гомуми иске төрки тел, иске татар әдәби теле, татар милли язма әдәби теле, хәзерге татар әдәби теле.

Ике теллелек. Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләре.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## Лингвистик анализ үрнәкләре

### СҮЗГӘ ФОНЕТИК АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ

1.Сүзне иҗекләргә таркатырга, басымын күрсәтергә.

2.Сүздә ничә аваз һәм хәреф барын билгеләргә.

3.Авазларны һәм хәрефләрне рәттән санап чыгарга.

4.Сузык авазларны рәттән санап чыгарга, әйтелешләрен билгеләп (калынмы-нечкәме, иренләшкәнме-иренләшмәгәнме), сүзнең сингарсонизм законына буйсыну-буйсынмавын ачыкларга.

5.Тартык авазларны рәттән санап чыгарга һәм әйтелешләрен билгеләргә (ясалу ысулы һәм урыны, яңгыраумы-саңгыраумы, ).

6.Аваз һәм хәрефнең бер-берсенә туры килмәгән очракларын билгеләргә һәм аңлатырга.

### СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕНӘ МОРФОЛОГИК АНАЛИЗ ЯСАУ ТӘРТИБЕ

**Исемгә анализ**

1.Ялгызлык яки уртаклык исем булуы.

2.Ясалышы.

3.Берлектә яки күплектә булуы.

4.Тартым белән төрләнгән булса, аның заты-саны.

5.Кайсы килештә булуы.

6.Кайсы сүзне ачыклавы (яки кайсы сүзгә ияртүе) һәм нинди җөмлә кисәге булуы

**Сыйфатка анализ**

1. Сыйфатның ясалышы.
2. Дәрәҗәсе
3. Кайсы сүзне ачыклавы һәм нинди җөмлә кисәге булуы.

**Рәвешкә анализ**

1.Рәвешнең төркемчәсе.

2.Ясалышы.

3.Кайсы сүзне ачыклап килүе һәм нинди җөмлә кисәге булуы.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Алмашлыкка анализ**

1.Алмашлыкнынтөркемчесе

2.Ясалышы.

3.Төрләнсә, нәрсә белән төрләнүе һәм нинди җөмлә кисәге булуы.

**Санга анализ**

1.Санның төркемчәсе.

2.Ясалышы.

3.Саналмышы булса, күрсәтергә, булмаса, ни өчен юк икәнен әйтергә.

4.Төрләнгән булса, нәрсә белән төрләнүен билгеләргә.

5.Туры яки күчерелмә мәгънәдә килүен күрсәтергә.

**Фигыльгә анализ**

1.Төркемчәсе.

2.Ясалышы.

3.Барлыктамы, юклыкта килүе.

4.Зат белән төрләнгән булса, заты, саны.

5.Заман белән төрләнгән булса, нинди заманда булуы.

6. Затланышсыз фигыль булса, кушымчасы; нәрсә белән төрләнүе; кайсы сүзгә ияреп килүе яки ачыклавы.

7. Нинди җөмлә кисәге булуы.

**Ярдәмлекләргә анализ**

1. Теркәгечнең төрен, кайсы сүз яки җөмләләрне бәйләвен әйтергә.

2. Кисәкчәнең кайсы сүзкә яки җөмләгә каравын, нинди мәгънә төсмере белдерүен әйтергә.

3, Бәйлекнең нинди килеш соравын һәм кайсы сүзләрне бәйләвен күрсәтергә.

СИНТАКСИК АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ

**Сүзтезмәгә анализ ясау тәртибе**

1.Сүзтезмәнең төзелеше: гади яки катлаулы булуы билгеләнә.

2.Ияручe һәм ияртүче сүзләрнең нинди сүз төркеме белән белдерерүенә карап, сүзтезмәнең төре билгеләнә.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

3.Ияруче сүзне ияртүчегә бәйләүче чара билгеләнә.

4.Ияруче сүз белән ияртүче арасындагы мәгънә мөнәсәбәте билгеләнә.

**Гади җөмләгә билгеләмә бирү тәртибе**

1.Оештыручы үзәкнең санына карап, ике яки бер составлы җөмләләр билгеләнә.

2.Мәгънә тулылыгы өчен кирәк булган кисәкнең булу-булмаавынакарап, җөмләнең тулы яки ким булуы күрсәтелә.

3.Әйтү максатына карап җөмлә төре әйтелә.

4.Чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки кире кагуына карап, раслау яки инкяр җөмлә күрсәтелә.

5.Иярчен кисәкнең булу-булмавына карап, җыйнак яки җәенке җөмләләр билгеләнә.

6.Аерым җөмлә кисәкләренә таркала алу яки алмавына карап, грамматик таркала һәм таркалмый торган төрләр күрсәтелә.

7.Җөмләдә тиңдәш яки аерымланган кисәкләр күрсәтелә.

**Кушма җөмләгә синтаксик анализ тәртибе**

1.Хәбәрлекләрне табарга һәм алар арасындагы мөнәсәбәтне билгеләргә (җөмләләр арасында ияртүле бәйләнеш булса, баш җөмләне табарга).

2.Иярчен җөмләләрнең (яки тезүле бәйләнештә торган хәбәрлекләрнең) чиген билгеләргә һәм бәйләүче чараны күрсәтергә.

3.Җөмләнең схемасын ясарга.

4.Җөмләгә билгеләмә бирергә.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## Беренче бирем

## *ФОНЕТИКА*

**1. Татар авазларын чагыштырган фонетик пропорцияләрне чишегез.**

***Үрнәк:*** [а]: [ә]=[о] : [Х] пропорциясе бирелгән. Аны чишү өчен, авазларга хас үзенчәлекләрне билгеләргә һәм, тигезләмәнең ике ягы да тигез булу тиешлегеннән чыгып, Хны табарга кирәк. Моның өчен авазларга характеристика бирәбез: [а] – арткы рәт, түбән күтәрелешле иренләшмәгән сузык;

[ә] – алгы рәт, түбән күтәрелешле иренләшмәгән сузык;

[о] – арткы рәт, урта күтәрелешле иренләшкән сузык;

[Х] = ?

[Х] ны табу өчен, ике бертөрле үзлекләрне төшереп калдырабыз һәм парсыз үзлекләрне җыябыз.

[Х]= алгы рәт, урта күтәрелешле иренләшкән сузык аваз. Бу нинди аваз?

[Х] = **[ө]**

| | | |
|---|---|---|
| [б] : [п] = [з] : [Х] | [д] : [м] = [н] : [Х] | [л] : [н] = [ч] : [Х] |
| [а] : [у] = [ә] : [Х] | [о] : [э] = [ө] : [Х] | [г] : [к] = [ж] : [Х] |
| [и] : [а] = [Х] : [ә] | [с] : [т] = [ж] : [Х] | [ү] : [ө] = [ы] : [Х] |
| [п] : [д] = [б] : [Х] | | |

**2. Җөмләләрне укыгыз һәм аваз үзгәрешләре кичергән берәмлекләрне табыгыз. Аларның төрен ачыклагыз.**

***Мәсәлән,*** *борынгы* сүзендә ирен гормониясе (беренче иҗеккә карап, калган иҗектәге сузыклар да иренләшкән) һәм кече тел ассимиляциясе (регрессив, контактлы ассимиляция) бар.

Хәзер милли-икътисади фикернең чыганакларын өйрәнүне җитди киңәйтеп җибәрү һәм баету, аның теоретик дәрәҗәсен, эчтәлеген тулырак ачу өчен яңа



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

мөмкинлекләр туды. Мәсәлән, бу - күренекле икътисадчы галим, педагог, язучы Муса Акъегетнең фәнни мирасын һәм иҗтимагый –сәяси эшчәнлеген өйрәнгәндә, тикшергәндә дәлилле күзәтелә. Муса Акъегет фикеренчә, проблеманы хәл итүнең иң кулай вариантын сайлап ала белү аның бик күп якларын, нечкәлекләрен бер үк вакытта өйрәнү һәм исәпкә алу нәтиҗәсендә генә мөмкин булачак.

(Ф. Газизуллиннан)

**3. Сүзләрне иҗекләргә бүлегез һәм иҗек калыпларын, төрләрен билгеләгез.**

***Үрнәк:*** *мәгълүмат* сүзендә 3 иҗек бар: [мәѓ-лү-мәт]. Беренче һәм өченче иҗекләр – ябык, икенче иҗек – ачык. Иҗек калыплары: ТСТ-ТС-ТСТ.

Мәгълүмат, яшерен, елга, ашъяулык, тау, аю, төньяк, тәкъдим, дәү әни.

**4. Түбәндәге сүзләрнең басымын билгеләгез.**

Китапханә, җырлармын, җыештырмагансыз, үзйөрешле, суыткыч, йөрмәгез, төрекчә, барыбыз да, шундый, синдәй, башваткыч, ләкин, кайчандыр, никтер.

**5. Текстка транскрипция ясагыз.**

90нчы еллар башында Финляндиядә яшәүче татарлар белән казанлылар арасында җанланып киткән элемтәләрнең күбесе нәкъ Айнур исеме белән бәйле дисәм, хата булмас. Казан дәүләт университетына килеп, ике ел ана теле, милли әдәбият өлкәсендә гыйлем өсти Айнур. Театр, концертларга йөри. Аны безнең татар дөньясы төрле яктан кызыксындыра. Болар аның йөрәгендә генә түгел, фотограф-рәссам буларак, альбомнарында да урын ала. Үзенең нәселе чыккан Сергач якларын, Казан каласын һәм дә үзе туган Финляндия илендә яшәүче милләттәшләренең гореф-гадәтләрен, көнкүрешен кинога төшереп, бу фильмнарны Хельсинкиның үзәк телевидениесеннән күрсәтүгә ирешә ул.

(З. Шакирҗан)

**6. Түбәндәге сүзләр арасыннан [W] авазы кергәннәрен табыгыз һәм аның нинди хәреф белән белдерелүен аңлатыгыз.**

Алтын Урда, тәбрикләү, гүзәл, тавыш, вәзир, вәкаләтле вәкиллек, тәүге, әүвәл, сәүдә, Варшава, табышмак, вакытлыча, матбугат, авырлык, гәүдә, кавын.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

7. **Түбәндәге сүзләрнең нинди орфографик принципка нигезләнеп язылуларын ачыклагыз.**

***Үрнәк:*** *Китап* сүзе фонетик принцип нигезендә языла.

Яңа, кыйммәт, аккош, сәлам, контроль, тәкъдим, юлчы, борынгы, унбиш, шагыйрь, цирк, хосусый, металл, Ижевск, өчпочмак, ямьсез.

8. **Татар теленең “Орфографик сүзлеге”ннән файдаланып, “ь” һәм “ъ” билгеләре куелуның һәр очрагына бишәр мисал языгыз.**

1) “ь” билгесе авазны йомшак әйтү өчен языла:
2) “ъ” билгесе авазны каты әйтү өчен языла:
3) “ь” билгесе иҗекне нечкә уку өчен языла:
4) “ъ” билгесе иҗекне каты уку өчен языла:
5) “ь” билгесе аеру вазифасын үти:
6) “ъ” билгесе аеру вазифасын үти:
7) “ь” билгесе һәмзә урынына языла:

9. **Дифтонглар – нәрсә алар? Күтәрелмә һәм төшерелмә дифтонглар кергән унар сүз языгыз.**

10. **Җөмләдәге сүзләргә фонетик анализ ясагыз.**

Як-якта, яшел стенадай булып, арыш басып тора; ерак та түгел, арыш арасында ялгыз көнбагышның сары башы күренә.

(И.Гази)

**Тестлар**

1. **Тел гыйлеме — …**

1) телне, аның яшәү һәм үсеш закончалыкларын өйрәнә торган фән;
2) төрле яктан телнең сүзлек байлыгын өйрәнә торган фән;
3) сөйләм төзелешен өйрәнә торган фән.

2. **Татар теле — …**

1) тамыр тел;
2) полиситетик тел;

11. **Татар телендәге [о] авазына кайсы характеристика туры килә?**

1) арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшкән сузык;
2) алгы рәт, урта күтәрелешле, иренләшкән сузык,
3) арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән сузык;
4) алгы рәт, урта күтәрелешле,



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

3) флектив тел;
4) агглютинатив тел.

**3. Аваз ул — …**

1) фонемаларның язуда белдерелүе;
2) тон һәм шау катнашында барлыкка килгән саңгырау берәмлек;
3) сөйләмнең таркалмый торган иң гади фонетик берәмлеге.

**4. Төрки телләрдә түбәндәге кушык авазларның кайсылары бар?**

1) дифтонглар;
2) трифтонглар;
3) ялган дифтонглар;
4) ялган трифтонглар.

**5. Сөйләм аппараты түбәндәге өлешләрдән тора:**

1) авыз куышлыгы, фаринкс, борын куышлыгы, бугаз куышлыгы;
2) авыз куышлыгы, борын куышлыгы, үпкәләр, йөз;
3) йоткылык, иреннәр, тешләр, аңкау.

**6. Авазларны сузыклар һәм тартыкларга нинди күрсәткечләргә карап бүләләр?**

1) акустик;
2) артикуляцион;
3) акустик һәм артикуляцион.

**7. Авазларның позицион үзгәрешләренә түбәндәгеләр керә:**

1) эпентеза, ассимиляция, редукция, протеза, метатеза;
2) ассимиляция, диссимиляция; сингармонизм;
3) эпентеза, протеза, редукция.

8. **Элизия ул** — …

1) чит авазны кабул иткәндә, аны туган телдәге аваз белән алыштыру;
2) ике сүзнең беренчесе сузык авазга тәмамланып, икенчесе сузыкка башланып, бер басым астында барлыкка килә торган үзгәреш;

иренләшмәгән сузык

**12. Яңгырау авазлардан гына торган төркемне табыгыз.**

1) б, ф, д, ш, к, ч
2) г, ж, җ, б, в
3) щ, х, т, с, ч, ц

13. **Тел алды авазын күрсәтегез**.

1) б
2) н
3) ң
4) х

**14. [w] авазына туры килгән характеристиканы күрсәтегез.**

1) ирен-ирен, өрелмәле, сонор, авыз авазы;
2) тел алды, ярым-йомык, сонор, авыз авазы;
3) ирен-теш, өрелмәле, шаулы, яңгырау аваз;
4) ирен-ирен, йомык, сонор, борын авазы.

**15. Татар телендә йоткылык (фарингаль) авазы ничәү?**

1) 1
2) 2
3) 3
4) 4

**16. Татар теленә хас булмаган иҗек калыбын табыгыз.**

1) СТ;
2) ТСТ;
3) ТТС;
4) СТТ.

**17. *Әлбәттә* сүзендә басым кайсы иҗеккә төшә?**

1) 1;
2) 2;
3) 3.

**18. Кырмысканы кымрыкса (диал.) дип әйткәндә нинди аваз үзгәреше чагылыш**



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

3) сүздәге авазларның урыннары алышыны.

**9. Сузык һәм тартыклар артикуляциясенең бер-берсенә җайлашуы ничек атала?**

1) ассимиляция;
2) аккомодация
3) сингармонизм;
4) диссимиляция.

**10. Татар телендә сузыкларны телнең горизонталь хәрәкәтенә карап төркемләгәндә нинди төркемнәр барлыкка килә?**

1) озын һәм кыска сузыклар;
2) иренләшкән һәм иренләшмәгән сүзыклар;
3) алгы һәм арткы рәт сузыклары;
4) югары, урта, түбән күтәрелешле сузыклар.

**таба?**

1) диэреза;
2) метатеза;
3) элизия;
4) субституция.

**19. *Табигать* сүзе нинди орфографик принцип буенча языла?**

1) фонетик;
2) морфологик;
3) тарихи-традицион;
4) график.

**20. Сүзгә дөрес транскрипция ясалган вариантны билгеләгез.**

1) [ķуәтлә];
2) [ķуwәтлә];
3) [ķүwәтлә];
4) [ķуатлә];

## Икенче бирем

ЛЕКСИКА

**1. Түбәндәге сүзләрне бер мәгънәле һәм күп мәгънәле берәмлекләргә аерыгыз.**

Бер, дус, урам, тел, кер, кадак, кара, йөз, таш, төш, сүзлек, йөк, корал, йозак, балдак.

**2. Күп мәгънәле сүзләргә һәм омонимнарга бишәр мисал языгыз. Алар бер-берсеннән ничек аерылалар? Аңлатыгыз.**

**3.Күчерелмә мәгънәле сүзләрне табыгыз, аларның төрен билгеләгез.**

Гөлләрнең былбылы булу өчен җырчы булу гына аз, опера сәхнәсе генә аз. Халык җырлары, романслар, композиторлар иҗат иткән чын җырлар кирәк. Бу яктан караганда, Зиләнең җыр иҗаты чәчәкле болынга тиң. Аларны җанны рәхәтләндереп тыңлау, теләгән кадәр ләззәт алу өчен айлар, еллар кирәк булыр иде. Аның җырларын тыңлаган саен бер хакыйкатькә ныграк төшенә барасың: чын



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

җырчы өчен ике гомер кирәк икән: берсе – җырларга өйрәнү өчен, икенчесе - җиренә җиткереп, рәхәтләнеп, тамашачы күңеленә “сандугач оялатырлык” итеп җырлау өчен.

(“Сөембикә” журналыннан)

**4. Омонимнар нинди сүзләр алар? Омонимнарның һәр төренә бишәр мисал язгыз һәм ни өчен шулай төркемләвегезне аңлатыгыз.**

**5. Бирелгән сүзләрнең синонимнарын табыгыз, доминанта сүзне билгеләгез һәм синонимик рәт төзегез. Сүзтезмәләр ярдәмендә синонимнарның мәгънә төсмерен ачыклагыз.**

***Үрнәк*: <u>яшәү-</u> гомер итү, гомер кичерү, тереклек итү, көн күрү, дөнья куу.** Татарстанда яшәү; туган җирдә гомер итү; озын гомер кичерү; хайваннарча тереклек итү; авыр шартларда көн күрү; байлар кебек дөнья куу.

Күп, батыр, уңган, тиз, көч.

**6. Бирелгән сүзләрнең синонимнарын табыгыз, һәрберсен антонимы белән алыштырыгыз.**

***Үрнәк:*** *бәйсез* (бәйле) – хөр (тоткын), азат (бәйле), ирекле (ирексез), мөстәкыйль (бәйле).

Яшь, керү, иртән, юмарт, ихлас.

**7. Тексттагы сүзләрнең килеп чыгышлары ягыннан кайсы телгә нисбәтле булуларын ачыклагыз.**

1999 елда татар сынлы сәнгатенең аксакалы Бакый Урманче музее ачыла. Ул Щапов урамындагы 20нче йортта урнашкан.

Өч катлы музей йортында Бакый Урманченың сынлы сәнгатьнең барлык өлкәләрендә иҗат иткән эшләре урын алган.

Бакый ага – татарның Кол Гали, Мәрҗани, Насыйри, Тукай Дәрдмәнд, Җәлил кебек шәхесләрнең образларын һәм үзенең замандашларының йөздән артык



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

график портретларын, скульптуралар, меңнәрчә этюд, пейзаж, шамаилләр эшләгән автор.

Музей ядкярләре арасында Урманченың мольберт һәм пумалалары, фотоларда сурәтләнгән алъяпкычы, үзенең шәхси тупланмасыннан сөлге-тастымаллары, атасы Идрис хәзрәтнең чапаны белән анасы Мәгъҗүбә абыстайның калфагы һәм башка әйберләр. Өстәлдәге папкалар да игътибарны җәлеп итеп тора.

(И.Минһаҗевадан)

**8. Бирелгән сүзләрнең кайсы төркемгә нисбәтле булуын ачыклап языгыз.**

*Тарихи сүзләр:*

*Архаизмнар:*

*Неологизмнар:*

*Искергән сүзләр:*

*Диалекталь сүзләр*:

Күмхуҗ, стахановчы, сәхабә, метагалактика, санак, плейр, вәзир, дәресханә, сыйхәт, (шифа) эстәү, вә, фалиҗ, кәшәтаяк, дастук, тал пипие, бәпчү, болгавыр, сканер, интерфлот, импичмент.

**9. Тел сүзе кергән 10 фразеологик берәмлек уйлап языгыз. Һәрберсенең нинди мәгънә белдерүен аңлатыгыз.**

**10. Төшеп калган хәрефләрне куеп, сүзләрне күчереп языгыз. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ннән файдаланып, аларның мәгънәләрен ачыклагыз.**

Ка…әр, зә..әр, и…тибар, падиша…, ..ан, …әвәскәр, ка…арман, җөм…үрият, …өнәр, җи…ангир, әрва…, …әйран, …әнҗәр, и…тыяр.

## Тестлар

**1.Этимология ул — …**
1) Ялгызак исемнәрне өйрәнә торган фән;
2) Сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә торган фән;
3) Сүзнең атау мәгънәсен, атама бирү

**11. Килеп чыгышы ягыннан сүзнең кайсы телгә нисбәтле булуын күрсәтегез.**

*мунчала*



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

закончалыкларын өйрәнә торган фән;
4) Телнең тотрыклы төзелмәләре җыелмасы.

**2. Күпер сүзе — …**

1) Бер мәгънәле сүз
2) Күп мәгънәле сүз

**3. *Имтиханда укытучы аны бөтенләй <u>коралсызландырды</u>* җөмләсендәге астына сызылган сүз нинди мәгънәдә кулланылган?**

1) Туры
2) Күчерелмә

**4. *Капкынга <u>кабу</u>* сүзтезмәсендәге астына сызылган сүз нинди мәгънәдә кулланылган?**

1) Туры
2) Күчерелмә

***5. Ярлы өйләр пычак кайрыйлар,***
***Ак сарайлар ашыгып хәйлә кора (Х.Т.)***
**шигъри юлларында күчерелмә мәгънәнең кайсы төре кулланылган?**

1) метафора
2) метонимия
3) синекдоха

**6. Омонимның төрен билгеләгез.**

***Бураннар басылды,***
***Басылды, күк ачылды, -***
***Бигрәк зәңгәр күк***
***Зәңгәр синең күзләр күк (Ш.Г.)***

1) Саф омоним
2) Омограф
3) Омофон
4) Омоформа

**7. Омонимның төрен билгеләгез.**

***Нишләтергә кәҗәбезне?***
***Аптыратты кәҗә безне (Р.М.)***

1) Саф омоним
2) Омограф
3) Омофон
4) Омоформа

1) татар
2) монгол
3) гарәп
4) рус

**12. Килеп чыгышы ягыннан сүзнең кайсы телгә нисбәтле булуын күрсәтегез.**

*тәрбия*

1) татар
2) монгол
3) гарәп
4) рус

**13. Кулланылыш сферасыннан чыгып, лексеманың кайсы төркемгә нисбәтле булуын билгеләгез.**

*Коптилка*

1) Гомумхалык лексикасы
2) Диалекталь сүз
3) Һөнәрчелек лексикасы
4) Жаргон сүз
5) Арго сүз

**14. Искергән сүзнең төрен билгеләгез.**

*Имана*

1) тарихи сүз
2) архаизм

**15. Фразеологизмны табыгыз.**

1) кулны сөртү
2) кул болгау
3) кулга кул тотыну
4) кул селтәү

16. **Фразеологизмга дөрес аңлатма бирегез**

*Арыслан йөрәкле булу*

1) батыр булу
2) куркак булу
3) хәйләкәр булу
4) ялагай булу

*17. **<u>Котыбыз</u>** алынып торган идек (М.Ә)* җөмләсендәге астына сызылган сүзнең кайсы эмоциональ-стилистик катламга нисбәтлелеген күрсәтегез



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**8. Парлы сүзләр нинди берәмлекләргә нигезләнеп барлыкка килгәннәр?**

***Чит-ят, бата-чума, әйләнә-тулгана***

1) Омоним
2) Антоним
3) Пароним
4) Синоним

**9. Антоним парларны табыгыз.**

1) Дискуссия — бәхәс
2) Кап — кап
3) Китү — калу
4) Әмер — фәрман

**10. Синонимик рәттәге доминанта сүзне табыгыз.**

1) Ризык
2) Нигъмәт
3) Ашамлык
**4)** Азык

1) көнкүреш сүзе
2) гади сөйләм сүзе
3) китап сүзе

18**. "Физика терминнары сүзлегеге" —**

1) энциклопедик сүзлек
2) филологик сүзлек

19. **Сәйфуллин, Хәмзин, Мәхмүтовларның "Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге" — …**

1) энциклопедик сүзлек
2) филологик сүзлек

20.**Синонимик рәтне табыгыз.**

1) гомер, тормыш, яшәү, тере булу, мәгыйшәт
2) гомер, тормыш итү, тереклек, хәят, яши белү
3) гомер, тормыш, яшәеш, хәят, тереклек, мәгыйшәт

## Өченче бирем

### СҮЗ ЯСАЛЫШЫ. МОРФОЛОГИЯ

**1. Тәкъдим ителгән сүз ясалыш ысулларына унар мисал уйлап языгыз.**

1) *Морфологик ысул:*

2) *Синтаксик ысул:*

3) *Морфологик-синтаксик ысул:*

4) *Лексик-семантик ысул:*

5) *Фонетик ысул:*

**2. *Июль, капиталл, авария, известь, фонарь* сүзләрен тартым белән төрләндерегез. Өченче зат берлектәге тартымлы исемнәрне килешләргә куегыз.**

**3.Тексттан исемләшкән сүз төркемнәрен табыгыз, аларга морфологик анализ ясагыз, ни өчен исемләшүләрен аңлатыгыз.**

Төш вкытлары җитәрәк, көн кисәк үзгәреп китте. Тау-тау ак болытлар,



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

куерып, салынкы кара кучкылга әверелде. Каты җил өй түбәсе саламнарын тузгыта; тирәкләр, яшь ботакларын җиргә чаклы иеп, зарланышкан сыман шаулаша башлады. Аннары, шыбырдап, яңгыр яварга тотынды…

Яңгыр, кисәк кенә башланган кебек, кисәк кенә узып та китте. Кояш чыкты. Яшел яфраклар өстендә энҗе бөртекләредәй тамчылар җемелдәшә башлады. Иң эреләре, берәм –берәм тәгәрәшеп, җиргә коелды.

Йомшак сары мамыклы бәбкәләрен ияртеп, казлар яңадан урамга чыкты. Алар шундый шук: әнә берсе күлләвеккә үк кереп китте, аның артыннан башкалары да калышмады.

Көнчыгышка таба китеп барган яңгыр болыты өстендә, дугаланып, салават күпере сузылды.

(М.Галәүдән)

**4. Төрле төркемчәдәге саннар кертеп җиде җөмлә төзегез. Кулланылган саннарны төзелешләре ягыннан тикшерегез.**

**5. Бирелгән җөмләдәге сүзләрне, алмашлыклар белән алыштырып, ничә вариантта тәкъдим итеп була? Мөмкин булган вариантларны языгыз.**

***Үрнәк:*** *Карт өянкеләрнең салынып төшкән ботаклары су эчәләр.*-
Аларның салынып төшкән ботаклары су эчәләр ; Карт өянкеләрнең шул ботаклары су эчәләр; Шул өянкеләрнең салынып төшкән ботаклары су эчәләр һ.б.

Алсу дәрестән кайткач, бераз ял итәргә уйлады.

**6. Сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең уртак һәм аермалы якларын табыгыз. Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп языгыз.**

**7. Түбәндәге фигыльләрне төшеп калган хәрефләрен куеп күчереп языгыз. Аларның төркемчәсен билгеләгез.**

Бу…м, ач…рга, яс..сы килә, җырлам…ча, аш…сым юк, ки..к, төз…рбез, кайм…ча, шөг…льләнмәс, хәтерлә…че.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**8. Бирелгән фигыльләрне төрле юнәлешләргә куегыз һәм, фигыльнең төрле формаларын ясап, таблицаны тутырыгыз.**

1) кер 2) ю 3) укы 4) бел

| | хикәя фигыль | боерык фигыль | шарт фигыль | исем фигыль | сыйфат фигыль | хәл фигыль | инфинитив |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Төп | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 |
| Кайтым | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 |
| Төшем | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 |
| Йөкләтү | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 |
| Уртаклык | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 | 1<br>2<br>3<br>4 |

**9. Бирелгән сүзләрнең төрле сүз төркемнәренә нисбәтле булуын җөмләләр белән дәлилләгез.**

Кер, бер, иң, ук, баш.

**10. Тулы морфологик анализ ясагыз.**

Адәм баласы йөрәк теләгәнгә колак салып яшәргә тиеш. Җан теләгәннән баш тарту кешелекне киметә, ярлылата. Эш исә һөнәр түгел. Яшьме син, картмы – хәрәкәт ит, тормышың бәрәкәтле булыр, тәнең сырхаудан арына торыр.

(Ә.Баяннан)



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

## Тестлар

**1. Татар телендә ничә мөстәкыйль сүз төркеме бар?**

1) 5
2) 6
3) 7
4) 8

**2. Түбәндәге сүз нинди сүз ясалу ысулы белән ясалган?**

*Ирле — хатынлы*
1) фонетик
2) морфологик
3) морфологик — синтаксик
4) синтаксик

**3. Ялгызлык исемнәреннән генә торган төркемчәне табыгыз.**

1) кеше, Алсу, исем, дуслык,“Болгар ” радиосы.
2) Клуб, пароход, завод, конфет.
3) “ Химиклар сарае”, Суворов, КамАЗ, “Карлыгач”

**4. Татар телендә ничә килеш формасы бар?**

1) 6
2) 7
3) 8

**5. Астына сызылган исем кайсы заттагы тартым белән төрләнгән?**

*Авылның бормалы юлы.*
1) 1зат, берлектә
2) 2зат, берлектә
3) 3зат берлектә
4) тартым белән төрләнмәгән

**6. Җөмләдәге тартымлы исем кайсы килештә кулланылган.**

*Үги ана яфрагын язын җыярга кирәк.*
1) Баш
2) Иялек
3) Юнәлеш
4) Төшем
5) Чыгыш

**12. Җитмеш өч -…**

1) тамыр сан
2) кушма сан
3) тезмә сан
4) парлы сан

13. **Билгеләү алмашлыгын табыгыз.**

1) теге
2) һәммә
3) нидер
4) беркайчан да

**14. *Тегеләр ни өчендер килеп җитмәделәр* җөмләсендәге астына сызылган алмашлык-**

1) исем алмашлыгы
2) сыйфат алмашлыгы
3) рәвеш алмашлыгы
4) сан алмашлыгы

**15. *Барча* —…**

1) тамыр сыйфат
2) тамыр алмашлык
3) ясалма сыйфат
4) ясалма алмашлык

**16. *Быел имтихан бирелмәде* җөмләсендәге фигыль -…**

1) затланышлы
2) затланышсыз

**17. *Килгәләгез* фигыле нинди юнәлештә?**

1) төп
2) төшем

**18. Сыйфат фигыль формасын табыгыз**

1) кайтмагач (килде)
2) язылмас (шигырьләр)
3) бармаска (булды)

**19. *Байтак*—**

1) билге рәвеше
2) хәл рәвеше

***20. Бәлки —***



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

6) Урын- вакыт

**7. Исемнең дөрес язылышын күрсәтегез.**

*Кызыл(…)түш*
1) ъ белән
2) ь белән
3) өстәмә билгесез, кушылып
4) өстәмә билгесез, аерым

**8. Яшькелт —…**

1) асыл сыйфат
2) нисби сыйфат

**9. Сыйфатның дөрес язылышын табыгыз.**

***Тар(…)рак***
1) ы
2) ъ
3) өстәмә хәрефсез

**10. Кайсы раслау дөрес?**

1) сыйфатлар килеш белән төрләнәләр
2) сыйфатлар кайвакыт килеш белән төрләнәләр
3) сыйфатлар килеш белән төрләнмиләр

**11. 2/3 —бу…**

1) чама саны
2) бүлем саны
3) тәртип саны
4) микъдар саны

1) тезүче теркәгеч
2) ияртүче теркәгеч
3) бәйлек
4) кисәкчә

***21. Соң —***

1) баш килешне сораучы бәйлек
2) юнәлеш килешне сораучы бәйлек
3) чыгыш килешне сораучы бәйлек

***22. Үк —***

1) үзе бәйләнгән сүздән алда килә
2) үзе бәйләнгән сүздән соң килә
3) үзе бәйләнгән сүздән алда да, соң да килә

**23. *Ай – һай!* — нинди ымлык ?**

1) эмоцианаль
2) императив

**24. *Ялт!* бу — …**

1) ымлык
2) аваз ияртеме

**25. –дыр / -дер —**

1) кушымча
2) теркәгеч
3) кисәкчә

## Дүртенче бирем

СИНТАКСИС. ПУНКТУАЦИЯ

**1. Ияртүче сүзгә карап, сүзтезмәнең нинди төрләре булырга мөмкин? Мөмкин булган барлык төргә дә мисаллар китерегез.**

**2. Түбәндәге мәгънә мөнәсәбәтләрен белдергән сүзтезмәләр уйлап языгыз.**

***Үрнәк:*** *процессның коралын белдерә* – каләм белән язу

Эшне башкару урынын белдерә; процессны башкаручыны белдерә; эшнең үтәлү вакытын белдерә; эшнең күләмен белдерә; предметның төсен белдерә;



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

эшнең үтәлү шартын белдерә; затның һөнәрен белдерә; предметның материалын белдерә.

**3. Гади җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз.**

Төшке аш вакыты җитте. Һава торышы көтмәгәндә үзгәрде. Йомшак мендәрләр кебек ак болытлар, каралып, яңгыр болытларына әйләнде. Җил. Көчле салкын. Иртән генә җылы иде югыйсә. Табигать ике сәгать эчендә үзгәрде дә куйды. Көз көз инде, барыбер үзенекен итә.

**4.Җөмлә кисәге буларак хәлнең нинди төрләре бар? Һәр төргә мисаллар китерегез.**

**5. Синтетик иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан ничә төре бар? Мөмкин булган төрләрнең һәрберсенә мисал китерегез.**

**6. Түбәндәге калыплар буенча җөмләләр уйлап языгыз. Аналитик иярчен җөмләләрне синтетик төре белән, ә синтетик иярчен җөмләләрне аналитикка үзгәртегез.**

***Үрнәк:*** **1)** *Көз җиткәч, кошлар җылы якларга китәләр.* - Кайчан көз җитә, шул вакытта кошлар җылы якларга китәләр.

1) Синтетик иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә**:**
2) Аналитик иярчен максат җөмләле кушма җөмлә:
3) Синтетик иярчен шарт җөмләле кушма җөмлә:
4) Аналитик иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә:
5) Синтетик иярчен күләм җөмләле кушма җөмлә:
6) Аналитик иярчен ия җөмләле кушма җөмлә:
7) Синтетик иярчен кире җөмләле кушма җөмлә:
8) Аналитик иярчен аергыч җөмләле кушма җөмлә.

**7.Тезүле бәйләнештәге җөмлә кисәкләре булган гади җөмлә языгыз. Аннан**



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**тезмә кушма җөмлә ясагыз. Соңыннан күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә төзегез.**

**8.Кирәкле тыныш билгеләрен куеп, текстны күчереп язгыз. Тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.**

Аның хәзер бер генә эше бар ул ялан таптарга ярата Һәр көнне иртәнге чәйдән соң ул озын карагай таягын тотып торнаныкыдай нечкә аякларын сыгындырып кына буш урамнан уза кырга чыга һәм юлсыз-нисез күзе караган якка таба китеп бара Берәр түбә җиргә менгәч озын таягын ике учлап ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора Хәзер мәсәлән Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел ә фәләненче бригаданың да төгәленче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр

(Ә. Еникидән)

**9. Кушма җөмләләрнең схемасын ясагыз.**

Хатын да уңайсызлануын яшерә алмыйча, кулындагы базар сумкасын бер кулыннан икенчесенә күчерә иде.

Идел болгарлары Алтын Урдага буйсынып яшәгән чорда үлгән кешеләр истәлегенә кабер ташлары куела торган булган.

Пароход инде күптән узып киткән, болытлар белән күк йөзе тукталып калган, тик Шәфика гына башының җиңелчәәйләнү рәхәтеннән баскан җирендә тик тора.

Көтелмәгән бер вакыйга булды: һич уйламаганда, Бәдрия карчык килеп төште.

Сәбәбе бар: адәм балаларының үткәнен, кемлеген,ниләр кылганын белмәгәнгә, мин аларның тышкы кыяфәтләрен күзәтәм.

**10.Текстка тулы синтаксик анализ ясагыз.**

Кешелек дөньясы бу сәнгатьне өйрәнү белән борын заманнардан бирле шөгыльләнә. Кешенең эчке дөньясын, аның күңел хасиятләрен өйрәнү кешеләрнең бер-берсе белән аралашуы турындагы фәнне үстерүгә булышлык итә.

"Күк йөзеннән дә гүзәлрәк тамаша бар: ул да булса кешенең эчке дөньясы!" -



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

Франциянең бөек язучысы Виктор Гюго әнә шулай дигән. Борынгы греклар, кешенең тәнендәге җаны кечкенә генә курчакка ошый, дип ышанганнар.

Аралашу культурасы дигәннән эллиннар башка халыклар белән контактларны, халыкара бәйләнешләрне аңлаганнар. Борынгы заманда греклардагы әдәп кагыйдәләре үзенә бертөрле халыкара эталон дип саналган. Полибий дигән тарихчының язуына караганда, Римның Эллада дәүләтләрендәге беренче илчеләре йомшак күңелле һәм инсафлы грекларны тупаслыклары белән, хисләрен тыя белмәүләре белән таң калдырганнар

(Вакытлы матбугаттан)

## Тестлар

**1. Түбәндәге җөмләдә хәбәрлекле мөнәсәбәттәге ничә сүз бар?**

*Фердинант, галстугын төзәтә-төзәтә, музыка ишетелгән якка китте.*

1) 1
2) 2
3) 3

**2. Хәбәрлекле мөнәсәбәт булсын өчен, ничә мөстәкыйль сүз булырга тиеш?**

1) 1
2) 2
3) 2дән ким түгел
4) ничә сүз булуы мөһим түгел

**3. Көн болытлы — …**

1) исемле сыйфат сүзтезмә
2) сыйфатлы исем сүзтезмә
3) сүзтезмә түгел

**4. Сиңа хәтле белү — …**

1) фигыльле бәйлек сүзтезмә
2) бәйлекле фигыль сүзтезмә
3) алмашлыклы бәйлек сүзтезмә
4) алмашлыклы фигыль сүзтезмә

**5. Эч пошыру — …**

1) ирекле сүзтезмә
2) фразеологик сүзтезмә

**6.** *Җәен без имтиханнар* тапшырачакбыз **җөмләсендә ничә сүзтезмә**

**13. *Өйдә дуслары гына утырып калган* җөмләсендәге ия — …**

1) гади ия
2) тезмә ия
3) кушма ия
4) иясе юк

14. ***Имтихан <u>сәгать тугызда</u> башланачак* җөмләсендәге астына сызылган сүз нинди җөмлә кисәге**?

1) аергыч
2) тәмамлык
3) вакыт хәле
4) урын хәле
5) күләм хәле

**15. Җөмләнең төрен билгеләгез.**

***Кырга чыга һәм күзе караган якка таба акрын гына китеп бара.***

1) гади җөмлә
2) тезмә кушма җөмлә
3) иярченле кушма җөмлә

16. **Иярченле кушма җөмләдәге баш җөмлә белән иярчен җөмләләрне бәйләүче чараларны күрсәтегез.**

*Тагын шунысы кызык: директорны күрәсе килү бишләтә, унлата көчәеп китте.*

1) көттерү паузасы
2) мөнәсәбәтле сүз
3) янәшә тору
4) кушымча



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

*тапшырачакбыз* **җөмләсендә ничә сүзтезмә бар?**
1) 4
2) 3
3) 2
4) 1

**7. *Бүген Алсуларга керәсе түгел!* җөмләсе — …**
1) раслау җөмлә
2) инкяр җөмлә

**8. *Мин йокларга телим!* —**

1) җыйнак җөмлә
2) җәенке җөмлә

**9. *Җыелышта әйтелгәннәр дөрес булып чыкты* —**

1) бер составлы
2) ике составлы җөмлә

**10. Җөмләгә кайсы характеристика туры килә?**

*Аңа әле өйдә дә шактый эләкте.*
1) гади, тойгылы, раслау, җәенке, бер составлы, тулы
2) гади, хикәя, инкяр, җыйнак, ике составлы, тулы
3) гади, хикәя, рслау, җәенке, бер составлы, ким

**11. *Аның сүзләре эчне пошыра башлаган иде* җөмләсендәге хәбәр …**

1) гади
2) кушма
3) тезмә

**12. *<u>Тел белән</u> кызыксынуларым күптәннән башланды* җөмләсендәге астына сызылган сүз нинди җөмлә кисәге?**

1) аергыч
2) тәмамлык
3) хәл
4) аныклагыч

**17. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.**

*Син аңла: мондый әсәр язарга ярамый.*
1) синтетик
2) аналитик

**18. Иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез.**

*Мин эш юктан тирә-юньгә күз салдым.*
1) аналитик иярчен сәбәп җөмлә
2) синтетик иярчен сәбәп җөмлә
3) аналитик иярчен тәмамлык җөмлә
4) синтетик иярчен аергыч җөмлә

**19. Катлаулы кушма җөмләнең төрен билгеләгез.**

*Гөлзифа Давытка таба елыша төште, янында сөекле кешең барда туңып утырырга әле монда!*
1) күп тезмәле
2) күп иярченле
3) катнаш

**20. Җөмләгә туры килгән схеманы табыгыз.**

*Беренче кат күрүләремнән*
*Кырык биш ел үткәч кимендә,*
*Кем уйлаган, Галимҗан абый,*
*Үксермен дип изге өеңдә… (Х.Т.)*

1) [ 2 ] ← ( 3 ) ← ( 1 )

2) [ 1] = [ 2] =[ 3]

3) [ 1 ] ← ( 2)

4) [ 3] ← ( 2) ← ( 1)



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com

**Өстәмә әдәбият исемлеге**

Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке. — Казань: КГУ, 1968. - 367с.

Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача этимологик сүзлеге.— Казан: Тат. кит. нәшр., 2001. - 227 б.

Зәйнуллин Җ.Г. Шәрык алынмалары сүзлеге. - Казан: Мәгариф, 1994. - 144 б.

Рамазанов Ш. Татар теле буенча очерклар.— Казан: Татгосиздат, 1954.–200 б.

Сафиуллина Ф.С.,Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. — Казан: Мәгариф, 2002. -407 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. 1. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. - 725 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. 2. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. - 725 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. 3. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. - 832 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. — Казан: КДУ, 1978. — 221 б.

Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. — Казан: Хәтер, 1999.- 256 б.



PDF created with pdfFactory Pro trial version www.pdffactory.com